ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Апас муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртергә:

1) әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә «Апас шәһәр тибындагы поселогы»ның, «Табар Черкене авыл җирлеге»нең һәм «Чүри-Бураш авыл җирлеге»нең;

2) әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә «Биеш авыл җирлеге»нең һәм «Каратун авыл җирлеге»нең;

3) әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә «Болын-Балыкчы авыл җирлеге»нең һәм «Югары Ындырчы авыл җирлеге»нең;

4) әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә «Дәвеш авыл җирлеге»нең һәм «Коштавы авыл җирлеге»нең.

**2 статья**

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 11 (II өлеш) әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 30 декабре
№ 151-ТРЗ

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләренең
<u>КАРТА-СХЕМАСЫ</u>

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Апас муниципаль районы чиге
-муниципаль берәмлекләр чикләре
-А-Б – «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең һәм Табар Черкене авыл жирлегенең уртак чиге
- Б-В – «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең һәм Чүри-Бураш авыл жирлегенең уртак чиге
- жирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар

- Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл жирлеге территориясе

- Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе

- Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районының Чүри-Бураш авыл жирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләре
карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Апас муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б – Биеш авыл жирлегенен һәм Каратун авыл жирлегенен уртак чиге
- жирлекләрнен административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Апас муниципаль районынын Каратун авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районынын Биеш авыл жирлеге территориясе
- Апас муниципаль районынын Биеш авыл жирлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районынын Каратун авыл жирлеге территориясе

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләре
карта-схемасы

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Апас муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б – Болын-Балыкчы авыл җирлегенең һәм Югары Ындырчы авыл җирлегенең уртак чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге территориясе

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләре
карта-схемасы

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына

4 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Апас муниципаль районы чиге

- муниципаль берәмлекләр чикләре

- А-Б – Дәвеш авыл җирлегенең һәм Коштавы авыл җирлегенең уртак чиге

- җирлекләрнең административ үзәкләре

- торак пунктлар

- Апас муниципаль районының Коштавы авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Апас муниципаль районының Дәвеш авыл җирлеге территориясе

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

**«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелә торган үзгәрешләр**

1 – 24 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Апас муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре
# **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 2 (1) – 6 (176) | - Югары Ослан муниципаль районы |
| 6 (176) – 25 (161) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 25 (161) – 29 (259) | - Тәтеш муниципаль районы |
| 29 (259) – 43 (247) | - Буа муниципаль районы |
| 43 (247) – 44 (252) | - Чуаш Республикасы |
| 44 (252) – 2 (1) | - Кайбыч муниципаль районы |

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Апас шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Әлмәндәр авыл җирлеге |
| 3 | Бакырчы авыл җирлеге |
| 4 | Биеш авыл җирлеге |
| 5 | Олы Болгаер авыл җирлеге |
| 6 | Зур Күккүз авыл җирлеге |
| 7 | Болын-Балыкчы авыл җирлеге |
| 8 | Югары Аккуҗа авыл җирлеге |
| 9 | Югары Ындырчы авыл җирлеге |
| 10 | Дәвеш авыл җирлеге |
| 11 | Ишеево авыл җирлеге |
| 12 | Каратун авыл җирлеге |
| 13 | Кызылтау авыл җирлеге |
| 14 | Коштавы авыл җирлеге |
| 15 | Сатмыш авыл җирлеге |
| 16 | Урта Балтай авыл җирлеге |
| 17 | Иске Йомралы авыл җирлеге |
| 18 | Табар Черкене авыл җирлеге |
| 19 | Тутай авыл җирлеге |
| 20 | Чирмешән авыл җирлеге |
| 21 | Чүри-Бураш авыл җирлеге |
| 22 | Шәмбалыкчы авыл җирлеге |

«Апас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Апас муниципаль районы»**
**муниципаль берәмлеге территориясе чигенең**
**картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Апас муниципаль районы Чуаш Республикасы, Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш һәм Буа муниципаль районнары белән чиктәш.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Чуаш Республикасы белән чиктәш җирдә Апас, Буа муниципаль районнары һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Аюкөйдергән авылыннан 1,8 км көньякта урнашкан 43 нче (247 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Апас, Кайбыч муниципаль районнары һәм Чуаш Республикасы чикләре тоташкан урында Аюкөйдергән авылыннан 3,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче (252 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 44 нче (252 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 450 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 550 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, урман полосасы буйлап 500 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,1 км, төньякка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 650 м, кабат төньякка таба 200 м уза, алга таба 20 м Каратун – Чирмешән – Олы Подберезье автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 20 м көнбатышка таба бара, аннары төньякка таба 800 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап уза, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бәрлебаш участок урманчылыгындагы 78 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 250 м, Каратун – Чирмешән – Олы Подберезье автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 50 м бара, аннары 70 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м, Каратун – Чирмешән – Олы Подберезье автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кабат кисеп үтеп, көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 64 нче, 65 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,3 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 11,2 км көньяк-көнчыгышка таба, инешләрне кисеп үтеп, «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бәрлебаш участок урманчылыгындагы 66, 67, 68, 69 нчы урман кварталларының һәм Балтай участок урманчылыгындагы 18, 19, 20, 21, 22 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 2,9 км төньяк-көнчыгышка таба 22, 17, 10 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап һәм 11 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 11 нче, 12 нче урман кварталларының

көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2,3 км төньяк-көнчыгышка таба 12 нче, 2 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 300 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба 2 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап һәм 3 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап, 150 м көнчыгышка таба, Апас муниципаль районының Урта Биябаш авылын һәм Кайбыч муниципаль районының Ябалак (Бүәле) авылын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 5,8 км көньяк-көнчыгышка таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтай участок урманчылыгындагы 3, 4, 5 нче урман кварталларының һәм Урсак участок урманчылыгындагы 55 нче, 56 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,7 км төньяк-көнчыгышка таба 56, 54, 49 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, 50 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап, 50 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 250 м көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба көнчыгышка 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м чокыр буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м чокыр буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м чокыр буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м чокыр буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба кибеп баручы инеш агымы буенча 1,0 км аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,6 км төньяк-көнчыгышка таба, Имәнле елгасын һәм «Олан – Каратун» – Олы Урсак автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,2 км төньякка таба инешкә кадәр бара, аннары урман массивының көнбатыш чиге буйлап 20 м уза, инеш агымы буенча 2,0 км өскә таба бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 59 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м һәм төньякка таба 400 м бара, алга таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Урсак участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 1,4 км көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап 1,0 км төньякка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 14 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 450 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба 13 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба 13 нче, 11 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 550 м аска таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап,

чокырны кисеп үтеп, 1,3 км төньякка таба, 300 м көнбатышка таба, 1,0 км кабат төньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба, Олан – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,0 км, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнчыгышка таба, су җибәрү канавын кисеп үтеп, үзәнлектәге сазлык буенча 350 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,7 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м көнчыгышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 250 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, урман массивының көньяк чиге буйлап 200 м уза, алга таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м үзәнлектәге сазлык буенча, төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 350 м үзәнлектәге сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман утыртмаларының көнбатыш чиге буйлап Апас, Кайбыч һәм Югары Ослан муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Аккуҗа авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче (1 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче (1 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үзәнлектәге сазлыкның көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 250 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көнчыгышка таба, 100 м агач-куак массивының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,0 км урман утыртмаларының төньяк чиге буйлап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зөя елгасына кадәр, аның текә сул ярын кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча 6,4 км өскә таба елганың сул ярына кадәр, әлеге елганың сул ярының текә ярлы участогы буйлап 100 м көньякка таба бара, алга таба «Идел буе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Чулпан участок урманчылыгындагы 68 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 3,5 км, көньяк чиге буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба Зөя елгасының сул ярына кадәр, әлеге елга яры буенча төньяк-көнчыгышка таба һәм елганың үзе буенча 40 м, елга агымы уңаена 1,9 км аска таба, Зөя елгасын кисеп үтеп, 40 м төньяк-көнчыгышка таба аның уң ярына кадәр, 67 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 300 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 2,0 км, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 63, 64, 66 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, әлеге инеш агымы буенча 1,8 км аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 100 м

көньякка таба, 50 м көнчыгышка таба, 100 м агач-куак массивының көньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м чокыр буйлап, сынык сызык ясап, 800 м төньяк-көнчыгышка таба, Казан – Ульяновск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м көньяк-көнчыгышка таба чокыр буенча, 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 69 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км төньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м төньякка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман утыртмаларының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м көнчыгышка таба, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,8 км көньяк-көнбатышка таба һәм 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба инешкә кадәр, Апас, Югары Ослан һәм Кама Тамагы муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Ясаклы Барыш авылыннан 1,3 км көнчыгышта урнашкан 6 нчы (176 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Апас, Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кече Болгаер авылыннан 6,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (161 нче) тоташу ноктасыннан алып Кече Шәкән елгасы буенча 3,2 км аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м төньяк-көнбатышка таба, 2,0 км төньякка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,2 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,6 км төньяк-көнчыгышка таба Кече Шәкән елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 2,3 км аска таба аның Олы Шәкән елгасына койган җиренә кадәр бара, сынык сызык ясап, 2,8 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча 100 м аска таба аның инешкә койган җиренә кадәр бара, инеш агымы буенча 2,6 км аска таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешнең текә ярын кисеп үтеп, 700 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 2,8 км көнбатышка таба бара, «Казан – Ульяновск» – Иске Барыш – Кама Тамагы» – Әлмәндәр автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньякка таба, сынык сызык ясап, 900 м төньяк-көнбатышка таба уза, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м Ока инешенә кадәр уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча 1,1 км өскә таба, төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м көнбатышка таба урман полосасы буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 400 м төньяк-көнбатышка таба, 500 м төньяк-көнчыгышка таба, 450 м төньяк-көнбатышка таба, 550 м кабат төньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнбатышка таба, 1,8 км төньякка таба, «Казан – Ульяновск» – Иске Барыш – Кама Тамагы

автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Коры Үләмә елгасына кадәр уза, Коры Үләмә елгасы агымы буенча 2,0 км өскә таба аңа коя торган Мәми елгасы тамагына кадәр бара, алга таба әлеге елга агымы буенча 1,1 км өскә таба 6 нчы (176 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 25 нче (161 нче) тоташу ноктасыннан алып 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, инешләрне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,4 км көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, 500 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 450 м урман утыртмалары буенча, сынык сызык ясап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 350 м көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба, чокырларны кисеп үтеп, 750 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 50 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 50 м агач-куак массивы буйлап Гремячий инешенә кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 3,5 км аска таба, 850 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 450 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Гремячий инешенең текә ярын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м карьер буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Үләмә елгасына кадәр бара, аннары әлеге елга агымы буенча 3,0 км өскә таба, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 800 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, инешне кисеп үтеп, 2,3 км көньяк-көнбатышка таба Турма инешенә кадәр уза, алга таба әлеге инеш агымы буенча 200 м өскә таба кибеп баручы инеш тамагына кадәр бара, аннары әлеге кибеп баручы инеш коя торган инеш агымы буенча 2,2 км өскә таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 50 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 39 нчы, 37 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, алга таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көнбатышка таба бара, аннары 900 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 500 м аска таба бара, алга таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м көньякка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 400 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 100 м, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Апас, Тәтеш һәм Буа

муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Төбәк Черкене авылыннан 1,2 км көньякта урнашкан 29 нчы (259 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 43 нче (247 нче) тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 50 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Чирмешән – Яльчик автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнчыгышка таба, 350 м көнчыгышка таба, 50 м көньякка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 1,7 км аска таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба, 1,1 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, инешкә кадәр 2,3 км бара, аннары инеш агымы буенча 950 м аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 750 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр, әлеге инеш агымы буенча 2,5 км аска таба аның Бла елгасына койган җиренә кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 6,5 км аска таба, 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын һәм Буа – Каратун автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба көньякка 500 м урман полосасы буйлап, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 600 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 350 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча 750 м аска таба, көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасы буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, көнчыгышка таба киптерү канавы буенча Зөя елгасына кадәр 350 м бара, әлеге елга буенча 20 м һәм аның агымы буенча 1,2 км аска таба уза, алга таба 30 м көньяк-көнчыгышка таба Зөя елгасы буенча аның уң ярына кадәр бара, аннары 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 450 м «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, төньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м агач-куак массивы буйлап Зөя елгасына кадәр уза, алга таба әлеге елга буенча 30 м һәм аның агымы буенча 7,9 км аска таба, елга буенча 20 м төньяк-көнчыгышка таба аның уң ярына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м көньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап,

авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м төньяк-көнчыгышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 17, 19, 21 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап, чокырларны һәм инешләрне кисеп үтеп, 2,3 км көньякка таба, 750 м көнчыгышка таба 21 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары көньякка таба 1,5 км урман массивының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 50 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, көньякка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Бәбки – Төбәк Черкене автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,9 км көньяк-көнчыгышка таба 43, 48, 49, 56 нчы урман кварталларының һәм, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 29 нчы (259 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Апас муниципаль районының**
**«Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Ишеево, Табар Черкене һәм Чүри-Бураш авыл җирлекләре белән чиктәш.

«Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Чүри-Бураш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Чүри-Бураш һәм Табар Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Биеш авылыннан 3,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, «Казан – Ульяновск» – Апас – «Олан – Каратун» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м көньяк-көнчыгышка таба, 100 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 800 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Табар елгасына кадәр уза, аннары әлеге елга агымы буенча 3,2 км аска таба бара, алга таба 2,8 км көньяк-

көнчыгышка таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Чүри-Бураш һәм Ишеево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Танай-Турай авылыннан 700 м көньяк-көнбатышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Ишеево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Ишеево һәм Табар Черкене авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Табар Черкене авылыннан 2,7 км көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м төньякка таба «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 28 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,4 км көнчыгышка таба, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 29 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы Дүртөйле инешенә кадәр бара, алга таба әлеге инеш агымы буенча 1,2 км аска таба уза, 100 м көнчыгышка таба буа буенча һәм кабат Дүртөйле инеше агымы буенча 50 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасы буйлап уза, алга таба, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 500 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 2,9 км урман полосасы буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Табар Черкене авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып 1,2 км көнбатышка таба «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 28 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, алга таба 2,2 км төньякка таба 27 нче, 25 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,2 км көнбатышка таба 25 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба 23 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Апас – Табар Черкене автомобиль юлына кадәр бара, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 2,0 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 1,3 км төньяк-көнбатышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба, чокырны кисеп үтеп, Табар елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 700 м аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньяк-көнчыгшка таба һәм 450 м төньяк-көнчыгышка таба 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Апас муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында» Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

## Апас муниципаль районының «Әлмәндәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Әлмәндәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әлмәндәр авыл җирлеге Олы Болгаер, Зур Күккүз, Ишеево, Чүри-Бураш авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш.

Әлмәндәр авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Әлмәндәр, Зур Күккүз авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Әҗем авылыннан 1,3 км төньякта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып Апас муниципаль районы чиге буйлап Әлмәндәр, Олы Болгаер авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Борнаш авылыннан 300 м көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әлмәндәр авыл җирлеге чиге Олы Болгаер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча, «Казан – Ульяновск» – Иске Барыш – Кама Тамагы» – Әлмәндәр – Кече Болгаер автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,7 км өскә таба уза, алга таба көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 70 м чокыр буенча, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Әлмәндәр, Олы Болгаер, Ишеево һәм Иске Йомралы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Болгаер авылыннан 1,8 км көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әлмәндәр авыл җирлеге чиге Ишеево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әлмәндәр, Ишеево һәм Чүри-Бураш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Марьино авылыннан 3,3 км төньякта урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнчыгышка таба, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 700 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әлмәндәр авыл җирлеге чиге Чүри-Бураш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба Әлмәндәр, Чүри-Бураш һәм Зур Күккүз авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Әҗем авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әлмәндәр авыл җирлеге чиге Зур Күккүз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба, төньяк-

көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньяк-көнбатышка таба һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, чокыр буенча 100 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап икенче кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары әлеге инеш агымы буенча 1,6 км аска таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба буа буенча бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м кабат аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, «Казан – Ульяновск» – Иске Барыш – Кама Тамагы» – Әлмәндәр – Кече Болгаер автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Апас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы<br>турында» Татарстан Республикасы Законына<br>5 нче кушымта

**Апас муниципаль районының**
**«Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бакырчы авыл җирлеге Кызылтау, Урта Балтай, Тутай, Чирмешән, Шәмбалыкчы авыл җирлекләре, Буа һәм Кайбыч муниципаль районнары белән чиктәш.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Кайбыч муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бакырчы, Чирмешән авыл җирлекләре һәм Кайбыч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Чирмешән авылыннан 3,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Апас муниципаль районы чиге буйлап Бакырчы, Шәмбалыкчы авыл җирлекләре һәм Кайбыч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Урта Биябаш авылыннан 2,5 км көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Шәмбалыкчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, чокырны һәм инешне кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтай участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталына кадәр, сынык сызык ясап, 1,4 км әлеге урман кварталының көнбатыш чиге буйлап Бакырчы, Шәмбалыкчы һәм Урта Балтай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бакырчы авылыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Урта Балтай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып 600 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 30 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 150 м көньяк-көнбатышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м һәм, Чирмешән елгасының текә сул ярын, елганың үзен һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 3,0 км көньякка таба, Каратун – Чирмешән – Олы Подберезье автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 2,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап Бакырчы, Урта Балтай һәм Кызылтау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызылтау авылыннан 1,9 км төньякта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Кызылтау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бакырчы, Кызылтау һәм Тутай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тәүгелде авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтай участок урманчылыгындагы 42 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, буаны кисеп үтеп, 550 м, 43 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 43 нче, 44 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,0 км уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 44 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, әлеге урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 100 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 450 м көньяк-көнбатышка таба 44 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Тутай авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балтай участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 40 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньякка таба һәм 300 м төньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, 40 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,0 км уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м, кабат авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба Бакырчы, Тутай авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Күкшем авылыннан 3,0 км төньякта урнашкан 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып Апас муниципаль районы чиге буйлап Бакырчы,

Чирмешән авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Аюкөйдергән авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Чирмешән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба Чирмешән – Яльчик автомобиль юлы буйлап уза, аннары 500 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Кайбыч урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бәрлебаш участок урманчылыгындагы 39 нчы урман кварталына кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка әлеге урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 300 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, әлеге инеш агымы буенча, Каратун – Чирмешән – Олы Подберезье автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,3 км аска таба аның Чирмешән елгасына койган җиренә кадәр бара, Чирмешән елгасы агымы буенча 1,4 км өскә таба Шайтан елгасы тамагына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча 1,9 км өскә таба буа плотинасына кадәр бара, плотинаны кисеп үтә һәм 100 м көнбатышка таба буа буенча уза, кабат Шайтан елгасы агымы буенча 1,8 км әлеге елгага кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча 650 м өскә таба 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Апас муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы<br>турында» Татарстан Республикасы Законына<br>6 нчы кушымта

## Апас муниципаль районының<br>«Биеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең<br>картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Биеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Биеш авыл җирлеге Болын-Балыкчы, Дәвеш, Каратун, Урта Балтай, Табар Черкене авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.

Биеш авыл җирлеге чиге Каратун авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Биеш, Каратун һәм Болын-Балыкчы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Биеш авылыннан 700 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 150 м көнбатышка таба, урман полосасын һәм «Казан – Ульяновск» – Апас – «Олан – Каратун» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба текә ярның төньяк-

көнбатыш чиге буйлап 50 м, текә ярны кисеп үтеп, 40 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба һәм 1,2 км көнбатышка таба, 900 м төньяк-көнчыгышка таба, яр буе урман полосасын кисеп үтеп, «Казан – Ульяновск» – Апас – «Олан – Каратун» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чигенә кадәр бара, алга таба 650 м төньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 30 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м көнбатышка таба сәнәгать объектының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне, аның текә ярларын һәм чокырны берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 900 м көньяк-көнчыгышка таба, әлеге инешне кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м төньяк-көнбатышка таба, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап, сынык сызык ясап, 200 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, канауны кисеп үтеп, 900 м уза, аннары әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полоса буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба Мурзинка елгасына кадәр бара, әлеге елга агымы буенча 1,1 км өскә таба уза, алга таба көнбатышка, 300 м урман полосасын кисеп үтеп, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Биеш, Каратун һәм Урта Балтай авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Балтай авылыннан 1,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Биеш авыл җирлеге чиге Болын-Балыкчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба «Казан – Ульяновск» – Апас – «Олан – Каратун» автомобиль юлына кадәр уза, аннары 2,0 км әлеге автомобиль юлы буйлап, Зөя елгасын кисеп үтеп, Биеш, Болын-Балыкчы, Табар Черкене һәм Чүри-Бураш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Биеш авылыннан 2,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Биеш авыл җирлеге чиге Табар Черкене авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 30 м, «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 2,6 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, Хващево күле буенча 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, Серебряный күлен кисеп үтеп, 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, канауларны берничә тапкыр кисеп үтеп, 3,6 км, чокырны кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 800 м төньяк-көнчыгышка таба «Буа урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 15 нчы, 16 нчы урман кварталларының төньяк

чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 2,6 км көньякка таба 16 нчы, 18 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 1,7 км көнбатышка таба 18 нчы, 17 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Биеш, Табар Черкене авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дәвеш авылыннан 1,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Биеш авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып Апас муниципаль районы чиге буйлап Биеш, Дәвеш авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дәвеш авылыннан 600 м көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

